КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 8 сентябрь г.Казань № б-2011

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 23 апрель, б-628 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, б-1581 нче; 2013 ел, 6 февраль, б-151 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, б-1846 нчы; 2013 ел, 4 декабрь, б-2477 нче; 2014 ел, 2 июнь, б-1039 нчы; 2015 ел, 23 гыйнвар, б-79 нчы; 2018 ел, 22 март, б-581 нче; 2020 ел, 29 апрель, б-865 нче; 2021 ел, 16 август, б-1544 нче; 2023 ел, 6 март, б-567 нче; 2023 ел, 27 декабрь, б-3150 нче; 2024 ел, 18 апрель, б-847 нче; 2024 ел, 11 июль, б-1512 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Медицина оешмалары тарафыннан мәҗбүри медицина иминияте системасы аша нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләүгә тарифлар буенча комиссия турындагы нигезләмәдә:

6 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

8 пунктта «һәм Комиссия беркетмәләрен саклау» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге боерык белән расланган Мәҗбүри медицина иминияте системасы аша нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру кысаларында медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләү тарифлары буенча комиссия составында:

комиссия составыннан М.М.Миңнуллинны чыгарырга;

Комиссия составына Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы, Комиссия рәисе Әлмир Рәшид улы Абашевны кертергә;

Гела Юрьевна Герасимованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары»;

Гүзәлия Камил кызы Зәкәриеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары, Комиссия секретаре»;

Никита Сергеевич Курзинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының сәламәтлек саклау, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә бюджет мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин